РУЗИЛ ФАЗЛЫЕВ

# КҮҢЕЛ ТАРИХЫ

ШИГЫРЬ. ТОМ 8. СТИХИ

Рузил Фазлыев

# Күңел тарихы.
# Шигырь. Том 8. Стихи

«Издательские решения»

**Фазлыев Р.**

Күңел тарихы. Шигырь. Том 8. Стихи / Р. Фазлыев — «Издательские решения»,

ISBN 978-5-00-591729-4

Гадилек байлыкМин авылның гади бер малае,Гади булыр, язган фикерләр.Вакыт кына ашыктырып әллә,Картаелып бераз кителгән… Биргәннәре әйтеп бетергесез,Язмыш итеп, куеп язылып.Бай икәнмен диеп шөкер итәм,Күңел төпләрендә казынып.Гадилектә тормыш рәхәте,Сырлы әйбер, тырный куңелне.Кеше сине ишетәдә кебек,Ипләп әйтә алсаң сүзеңне.

ISBN 978-5-00-591729-4

© Фазлыев Р.
© Издательские решения

# Содержание


| | |
|---|---|
| Ерак ара | 6 |
| Үз арбаң | 7 |
| Кирәк, кирәк | 8 |
| Хыял белән | 9 |
| Гәепме | 10 |
| Саннар | 11 |
| Тыңламаска | 12 |
| Тегенди | 13 |
| Алдану | 14 |
| Ә акыл кая | 15 |
| Өметле юл | 16 |
| Сабак | 17 |
| Ялгыз җан | 18 |
| Үзең кара | 19 |
| Җылы белән якты | 20 |
| Юл табу | 21 |
| Холык | 22 |
| Ак томан | 23 |
| Күләгә | 24 |
| Хаклык | 26 |
| Ник караңгы? | 27 |
| Ядкәрсез | 28 |
| Үзе җыры | 29 |
| Агым кебек | 30 |
| Кыйбласыз… | 31 |
| Иманга юл | 32 |
| Кайда сере | 33 |
| Бәллүр савыт | 34 |
| Талантмы… | 35 |
| Кызган, аз гына | 36 |
| Карлар көрим | 37 |
| Кар астында | 38 |
| Ихласлык | 39 |
| Тупик | 40 |
| Мирас | 41 |
| Язмыш бүлү | 42 |
| Хаклык | 43 |
| Озын кыска юл | 44 |
| Ул чаклар | 45 |
| Китү, кайту юллары | 46 |
| Баскыч | 47 |
| Февраль | 48 |
| Ялгыз, сәләмсез | 49 |
| Конец ознакомительного фрагмента. | 50 |

# Күңел тарихы
# Шигырь. Том 8. Стихи

# Рузил Фазлыев

© Рузил Фазлыев, 2022

ISBN 978-5-0059-1729-4 (т. 8)
ISBN 978-5-0056-9347-1
Создано в интеллектуальной издательской системе Ridero

# Ерак ара

Кеше күңелендә туа,
Уйлар хисләр фикерләр.
Юлларын таба алганда,
Еракларга җитерләр…

Хатлар аша хисләр йөргән,
Язулар җиргә килгәч.
Догаларга аралар юк,
Ихластан кыла белгәч.

Шулай булгач, туган уйлар,
Калмый гел күңелләрдә.
Өметләргә барып житә,
Бик ерак күренгәндә.

Тотып карап булмасада,
Аннан көчлениләр бар…
Бу тормышның бәрәкәтен,
Кешеләргә бирә алган.

Кешеләрне бәйли торган,
Сагынуларда е专ктан…
Хисләр өчен күңелләр бар,
Тавышларга колак бар.

Күңелләрдә сөйләшәләр,
Ишетә алучы булса..
Кеше хисе, уйларына,
Күңелең сизгер торса.

## Үз арбаң

Кеше арбасында бару диләр,
Барган юлың синнән тормаса.
Иярәсең яки ияртәләр…
Үзеңнеке әгәр булмаса.

Үз тормышың, үзе хыялларың,
Дусларың һәм якын туганнар.
Җирең телең илең динең уең,
Синең үзеннеке булганнан.

Ябышмыйча кеше арбасына,
Үз юлыңнан бара алганнан.
Колы булмый җирдә берәүнең,
Син ирекле булып калганнан.

Коллык бары Аллаһ алдында,
Чөнки язмыш аңа бәйләнгән.
Тормыш җилен үзең тоя алып,
Үз арбанда узу җәйләрдән.

Үзе арбаң тәүге бишек кебек,
Кошлар өчен оя шикелле.
Шул арбада бара алса гына,
Кеше күңеле туя шикелле.

# Кирәк, кирәк

Юлсыз җирдә юллар эзләгәндә,
Егылыпта… була абынып…
Бер Аллаһка бары табынып,
Гөнахлардан була арынып.

Атламыйча алга барып булмый,
Суга керми ничек йөзелә…
Тәүбәләрдән качып яшәгәндә,
Юллар бер көн барыбер өзелә.

Яшәгәнне ак караны бутап,
Синең өчен кемнәр аера.
Ышанычмы соңгы бер минутка,
Җитмәслек бит тулы аеда.

Кичерүче бөтен гөнахларны,
Бары, Ул бит сорый алганда.
Кем белә ала, соңгы халәтеңне,
Алданырак кирәк аңларга.

Кирәк, кирәк, әллә ниләр кирәк,
Кирәкмәгәннәре ник кирәк?
Иң кыены шушы ике әйберне,
Аера ала белү… бик сирәк…

# Хыял белән

Нинди була,
Ала хыяллар.
Нинди төскә,
Алар буялган.

Кайчан алар,
Бездә уянган…
Кемнәр теләп,
Үзе туя алган.

Әллә акыл,
Инде җуелган.
Хыял сүзе,
Алга куелган.

Алда барып,
Гомер юлында,
Ул уйлыймы,
Синең турында.

# Гәепме

Артык үкенүләр булмасынга,
Булу кирәк сабыр күңелле.
Язмышыңа син бит хуҗа түел,
Үлчәп сөйләү кирәк сүзеңне.

Кеше язмышыны кагылганда,
Гөнахларны уза алдашу…
Киләчәккә яралары булып,
Эзсез генә һичтә калмас ул.

Өметләрнең җимерелүләре,
Исраф булган сөю язлары.
Үкенепме яки җиңел уйлап,
Язмышларга диеп язганы.

Тирәнлеген күңел хәсрәтен,
Яра салган аңлый алырмы…
Бер гәепсез итеп үзен сизеп,
Җәзә алмый гына калырмы.

# Саннар

Буламы соң борчылырга,
Гомерләр диеп кыска…
Озынлыгын кемнәр белә,
Үтмәсен генә бушка.

Озынлыгы күренми шул,
Йомгаклар сүтелмичә.
Сәфәрләрдә була алмый,
Юллары үтелмичә..

Саннар, саннар саныймы,
Киләчәкә юлларны…
Саннар белән язып булыр,
Бары үткән, булганны.

Үтелгәндә, серле сандык,
Ә, үтелмәгәннәре…
Могҗизадай булмый мени
Бердә көтмәгәннәре.

Аңлагандай булам кебек,
Аңламастай булганны.
Әллә барсы аңлау гына,
Гомер инде узганны

# Тыңламаска

Камил акыл, иман эзләр дигән,
Картайгачтан, олы бер галим.
Вакыт шулай куша ахырысы,
Шуңа иман ягына карыйм.

Күңел безне гелдә әйдәп бара,
Юл күрсәтергә ул омтыла.
Кайвакытта кемне тыңлаптыр,
Күңел бар икәне онытыла.

Күпме уйлар кала күңелләрдә,
Гамәлләргә күчә алмыйча.
Ул бит безне бары чакыручы,
Бездән башка гына бармыйча.

Акыл-китап, гыйлем-күңел кебек,
Ничек аңлап, тотып карыйсың…
Тыңламаска, әллә теләп шулай,
Җавап эзләп күберәк арыйсың.

Тырышкан бит юлын таба ала,
Теләмәгән эзли сәбәбен…
Күңелләрдә әллә керләнәме,
Бозып яшәп тормыш әдәбен.

# Тегенди

Читтән карап шулайдыр да,
Тегенди… мондый кебек.
Кеше күңелен күрмичә,
Ничек әйтәсең белеп…

Сиңа ошамаганнары,
Сиңа чит булганнары.
Күңелләре ачылмыйча,
Ябылып торганнары…

Сәер кебек яшәгәннәр,
Тормышларда җирдәге.
Көзгедәге кебекме әллә,
Сыйфатларың синдәге.

# Алдану

Безне ничек алдыйлар,
Алдамыйча калмыйлар.
Булганнарын җимерәләр,
Яңаларын салмыйлар.
Коллар кебек яллыйлар.

Аңламыйлар түгел алар,
Алдау юлын аңлыйлар.
Тар барин диеп атыйлар,
Татар дия алмыйлар.
Аңлашуга бармыйлар

Аларча булмаганнары,
Барысыда дошманнар.
Син шпион… сатлыкҗан,
Үтсәң алар кушканнан…
…Кирәк бары куштаннар.

Түбәнерәк ия алар…
Бөгелсә әгәр билләрең.
Тураерга тиеш көтәргә,
Алар рөхсәт биргәнен.
«Миһербан"лык килгәнен.

Тар илгә ошыйдырда,
Мондый тормыш арбасы.
Чын татарның язмышы,
Җавап бирми калмасы.
Болай яши алмасы…

# Ә акыл кая

Акыл биргән безгә бу язмышта,
Башта булса, никтер күренми.
Тәртип ясап кеше гамәлендә,
Тормыш белән бергә үрелми.

Кеше башлы, берәү бәхәсләшми,
Ә акылы кая җыелган…
Исраф булып югалмасын өчен,
Тирәнгәме яшереп куелган.

Ул кирәк бит, янда гына булу,
Кирәк чакта киңәш алырга.
Дөрес фикереңә килә алып,
Ялгышлардан котылып калырга.

Ничек кулланасың акылыңны,
Ни икәнен аның белмәсәң.
Хак икәнгә үзең инанмыйча,
Акылым бар диеп йөрмәсәң.

# Өметле юл

Барган саен гел барасы килә,
Күргән саен килә күрәсе…
Ничә генә еллар яшәсәдә,
Һәркемнеңдә килә «түзәсе»..

Яшәү асылыда шунда ахыры,
Авырлыклар шуңа үтелә.
Үткәннәргә күчеп онытылып,
Булачаклар алда көтелә.

Юллар беткән кебек булып ала,
Алар кабат, тагын табыла.
Сүнә инде диеп уйлаганда,
Өмет учаклары кабына.

Көчләр җитмәс кебек тоелганда,
Әллә каян килеп җитәләр.
Чарасызлык аша үтәр өчен,
Теләкләрне күпер итәләр.

Аңлау кыен бөтен хикмәтләрен,
Безгә язмыш үзе биргәнен.
Белмисеңдә… шуңа эзлисең,
Гомер буе үзеңә дигәнен.

# Сабак

Бу дөньяда күргән белгәннәр,
Гыйлем итеп җыйган әйберләр.
Нинди генә сәфәр булсада ул,
Юлда кирәк булыр әйбер бар.

Иң күбесе сабак-ялгышлар шул,
Хәтерләрдә кала сакланып.
Кайберләре кабатлана әле,
Сабак була алмый акланып.

Тормыш мәктәбедәй ялларсыз,
Өйрәтәдә безне өйрәтә.
Өй эшләре тикшергәндәй итеп,
Бастырып кабатлата, сөйләтә.

Тәүгесе, тормыш башлар өчен,
Ак караны аера белергә.
Бусагадан атлап чыга белеп,
Кирәк чакта кире керергә.

Бутамыйча ишек тәрәзәне,
Югалтмыйч нәсел җебеңне.
Тыйнаклыкта, горурлыкта булып,
Саклар өчен җирдә йөзеңне.

# Ялгыз җан

Алдагыны алдан белмәсәңдә,
Үткәннәрне күреп барасың…
Күпме җаннар җиңел акыл белән,
Уйламыйлар ялгыз каласын.

Ялгызлык ул авыр гына түгел,
Якын кебек упкын читенә…
Моңнар баскан күңел белән бергә
Җан дигәнең, ялгыз ителә.

Җирдә тормыш туктап тора алмый
Уйланырга булмый вакытлар…
Җылы табып була ала мени.
Ялгыз җанга… үткән вакыттан…

Ялгызлык ул югалтулардан соң,
Сыенырга урын калмаса…
Беркем килеп ишек шакымаса,
Дөньялыкта искә алмаса…

Өметсезлек шайтан гәмәлелә,
Сыенырга кирәк Аллаһка…
Җирдә чакта якыная алып,
Мәңгелектә ялгыз калмаска!

# Үзең кара

Ышанмыйсың икән,
Башта сынап кара.
Тәмен белү өчен,
Тотып кабып кара..

Торалмыйча озак,
Ялгыз ятып кара.
Көчне җыя алып,
Торып басып кара.

Эшли алганнарның,
Торыр хакын кара.
Вакыт дигәннәре,
Күптән үтеп бара.

Юллар үткәннән,
Эзләр нинди кала.
Ара ерагая, нидер
Якыная бара.

Өметләрең бетеп,
Хыялларың кала.
Тормыш бизәгендә,
Буяуларың кала…

# Җылы белән якты

Күңел сорый кебек, күңел…
Шуңа барсын җирдә кыласың.
Булганнары таудай булсада,
Фәкыйрьлектә кебек буласың.

Күңел сорый кирәгендә кебек,
Җитмәгәнне, тыныч булырга.
Хыял әллә аны котыртамы,
Хыял сарайлары «корырга».

Кем туктаган савытлары тулып,
Яңаларын ясап куймыйча…
Мөмкинме соң аны тыңламыйча,
Кеше күңелләре туймыйча.

Нигә кирәк чиксез тырышулар,
Күңелеңне тыныч итмәсә…
Тынычлыгы әллә югаламы,
Җылы белән якты җитмәсә.

# Юл табу

Кеше борылып карый башлый,
Балачакка, тормыш башына.
Язмыш юлларыннан барсада,
Үзе бара язмыш карышына.

Дөнья куу, ни соң асылында,
Артта калмау өчен ашыгу…
Карамыйча тормыш хәлләренә,
Гади генә еллар алышыну.

Уйлап таба кеше авырлыклар,
Бер сәбәпсез тигез урында.
Исрафка китә күпме гомер,
Мөмкинлекләр чакта кулыңда.

Адашкандай гомер буе кеше,
Инкарь итеп булган юлларны.
Бутый бутый тыелганнар белән,
Ничә буын җирдә кылганны…

Ят юлларда… алар яңа түгел,
Алар инде безне алдаган.
Нигә кабат теләп адашырга,
Башка юллар әллә калмаган?

# Холык

Кешене, аера кешедән,
Сыйфаты яшәве серләре.
Тоемлай алырга сәләте,
Ул үзе бары тик белгәне.

Кылына даими гамәлләр,
Әйләнеп баралар гәдәткә.
Канунда калырга, сәбәптә,
Сакланып калынса, әдәптә.

Әдәптә кылынган гамәлләр,
Кешенең иң күркәм холыкы.
Кешедә булганы күренә,
Эчендә, холыкның олысы.

Була ул «җиңелдә», ««авырда».
Кайвакыт «холыксыз"исеме.
Холыкка бәйләнеп тормышта,
Ачыла язмышның ишеге.

Барсыда бер бөтен шикелле,
Берсенә бересе бәйләнә.
Гамәлдә, гәдәттә, холыкта,
Язмышның җебенә әйләнә.

# Ак томан

Кояшта юк, йолдызларда,
Алда тоташ ак томан…
Ак томаннар уртасында,
Югалып басып торам…

Сукмагымда, юлларымда,
Күренми. ак томанда…
Андый томан булмый иде,
Барыр юллар булганда.

Әллә юллар күренмәскә,
Каплананалар томанга.
Үтелмичә калганнары,
Аяз, якты… торганда…

Томан бит ул томан гына,
Түгел ул күтә алмаслык.
Билгесезлекләр булсада,
Булмый ул үтә алмаслык.

Таралырмы ак томаннар,
Барыр юлларны ачып.
Килмый әле югаласы,
Ак томаннарда «качып».

# Күләгә

Барган юллар, караваннар,
Янәшәдә бара, күләгә.
Эссе чүлдә кемнәр генә,
Күләгәсез юлда түзәлә.

Бер ягында исә кызу җиле,
Икенче ягында күләгә.
Эсседә пешкән урыннар,
Күләгәдә бары төзәлә.

Күләгәнең эзе кала алмый,
Ул барада бара, иярә…
Күләгәләреңдә синеке,
Үзең генә аңа иядә.

Күләгәләр күренәләр янда,
Яктыртучы нуры булганда,
Күләгәдә хәрәкәттә була,
Бары үзең бара алганда.

Эсселектән (анда) коткаручы,
Күләгә кемгәдер булыр дигән.
Күләгәсе туктап кала икән,
Димәк… инде шунда килгән…

Юк мени мондый хәл тормышта
Баручы арба артында атлар...
Эттереп баручы артыннан,
Каядыр ашыгыучы картлар.

Киресенчә бераз киресенчә,
Уйлар килә эшләр бетүгә.
Болай ашыгуның җимеше,
Кирәк... вакытлары үтүгә.

Рузил Фазлыев



# Хаклык

Үкенмә үткәнгә,
Борчылма көткәндә.
Бәхетле мизгелләр
Шөкерләр иткәндә.

Шөкерләр бүгенгә,
Булганга, күргәнгә.
Өстәлеп гамәлләр,
Ниләрдер белгәнгә.

Җыела бөртекләп,
Бәхетле минутлар.
Бүләктер киләчәк,
Кайгыңны онытсаң.

Тынычлык күңелдә,
Сиздерми урнашса.
Аннанда бәхетле,
Минутлар булмаста.

Син көтә белгәндә,
Өметле – киләчәк…
Көтмәгән… көткәнең,
Барысында бирәчәк.

Үткәрә белгәндә,
Шатлыкны тынычта.
Язмышның бер көне,
Бирелми бурычка.

# Ник караңгы?

Алышына көннәр төннәр белән,
Яктылыгы бөтенләй калмады.
Кышкы төннәр кебек озагырак,
Караңгылык шулай алдады…

Караңгылык никтер күңелләрдә,
Чарасызлык әллә яулады…
Шатландырмый инде кешеләрне,
Ап ак карлар кышын яуганы.

Өстән төшә олы алданулар,
«Тукмач» белән тулган колаклар.
Хәкимият уен уйнагандай,
Кора безгә матур тозаклар.

Хак булганга 2—3 ялган өстәп,
Ышанырлыгы… югала…
«Көтүчеләр» әллә кая куа,
Кая таба халык юл ала…

Кыйбыласыз әллә яшәгәнгә,
Тормыш яктылыгы кителде.
Түрә көтүенә ышанулар…
Чарасызлык кына китерде

# Ядкәрсез

Канатларсыз очу мөмкин түгел,
Я булмаса, тимер канатлар…
Самолетлар канатсызлар өчен,
Кошлар юлын гына кабатлар.

Чишмәләрдә, ага башлар өчен,
Күренмәгән юллар тапканнар.
Шул юллардан озак еллар буе,
Акканнарда, алар акканнар.

Иман нуры тоеп күпме буын,
Кыйбыланы таба алганнар.
Адаштыручылар килгәндә дә,
Үз кыйбыласында калганнар.

Булганнарнын нигә кадере юк,
Бәлки безгә җинел килгәнгә…
Безгә кәдәр тормыш итүчеләр,
Безнең өчен табып биргәнгә.

Зәгыйфлеге кеше күңеленең,
Бердәм булып яши алмавы.
Яшәп китеп әрәм шәрәм итеп,
Ядкәр булып берни калмавы.

# Үзе җыры

Үзе җыры була һәркемнеңдә,
Язмышына аның язылган.
Туа башлап тәүге авазлары,
Иң беренче аның языннан.

Кем ишетә, кем ишетә алмый,
Күңелендә туган моңнарын.
Ул барыбер аны тоеп яши,
Үзе өчен генә булганын.

Охшашлары аны үзенә тарта,
Чит тарафлардан агылса…
Таныш кебек хисләр агымы,
Күңеленә аның кагылса.

Аңлатырга яки күрсәтергә,
Тибрәлешен күңел кылларын.
Үз мәкәмен, үзе көйләренә,
Кеше куша булган моңнарын.

Үзе төсе, үзе җыры булып,
Сере булып калып күңелдә.
Үзе өчен генә җыр туганын,
Аңлаулары мөмкин түгелдә.

# Агым кебек

Еллар үтә һаман, ага сулар ага,
Әйтер сүзләр һаман бар әле.
Каян моңы шулай юллар табып ага,
Шул моңнарны тыңлап кал әле.

Ага еллар ага, кайсы якка таба,
Барыр юллар әллә билгеле…
Әллә хәзер генә, соң булсада
Юлдан бара белү килдеме…

Тау ташларда түгел, бары тигезлектә
Хәзер барган минем эзләрем.
Әллә гомер буе, үзем аңламыйча,
Шушы сукмакларны эзләдем…

Офыкларга таба ахры юллар бара,
Якыная ара… якын шикелле…
Моңнар мине шулай озатуы булды,
Әллә инде барып җителде…

# Кыйбласыз…

Карыйк әле бераз тирә якка,
Ашыкмыйча… дөнья качмас ул.
Теләсәңдә әгәр буйсынмасаң,
Яңа хикмәтләрен ачмас ул.

«Хуҗалар» күп, көтүчеләр кебек,
Көтү, көтү итеп «туплыйлар».
Шул көтүгә теләп кушылучы…
Кеше булуыннан «туктыйлар».

Үзе теләгенә хуҗа булмый,
Көтүчегә карап өметтә.
Ә син аңа бары мал көтүе
Сине уйламый ул… көлептә.

Хәкимнәр бит булган электә,
Аларда бит булган зирәклек.
Мәкер белән яшәп калу түгел.
Халык өчен булган кирәклек.

Вакыт килеп үзе сүзен әйтер,
Иелерләр «башлы» башлары.
Сүзсез калып инде мәнгелеккә,
Истәлеккә куйган «ташлары».

Табынырга була алга таба,
Исән чакта куйган ташларга.
Әллә аңлап, без кеше бит диеп,
Кыйбыланы эзли башларга.

# Иманга юл

Барыр юллар төрле төрлечә,
Гомер буйларына җитәрлек.
Вакытында, юлга чыга алсаң,
Ул юлларны бары үтәрлек.

Араларда күпме үзенчәлек,
Кабатлана яки үзгәрә.
Җәйләреңдә үтелмәгәннәре,
Кала ала икән, көзгәдә.

Графигы язган булмасада,
Вакыт куша, вакыт чакыра.
Кая баруыңны аңламыйча,
Ник чыгарга юллар чатына.

Ник көтәргә, вакыт туктамый бит,
Бүгеннекен бүген үтәргә…
Йомгагыңны тотып утырмыйча,
Кирәк аны кирәк сүтәргә.

Кояш баеганда юлга чыгу,
Хәерлеме, белсәң аңласаң…
Аз булсада бәрәкәте булыр,
Юлга чыга алмый калмасаң.

# Кайда сере

Җырның сере кайда, тирәндәме,
Якын гына, әллә өстәме…
Тавыш матурлыгы җырчының,
Алар биргән матур төстәме.

Көендәме, аны җыр итәрлек,
Көе барып ятса күңелгә.
Сакланамы икән онытылмый,
Кичәге җыр әле бүгендә…

Сүзләреме аның асылында,
Шигырь булып җиргә туганнар.
Күпмеләре сүзләр булып калып,
Моңнар белән тулы булганнар.

Җырчы була, җырлар булганда,
Көйләр генә, була алмый җырлар.
Өчеседә кушылганда. гына,
Моң чишмәсен һәр күңел тыңлар.

Берәү тыңлар якын җырчысын,
Икенчеләр җырның моңнарын.
Кемдер тыңлар, табар асылын,
Ни турында җырның булганын.
Нинди хисләр белән тулганын.

# Бәллүр савыт

Кайсы кыйммәт, бәллур савытмы,
Әллә салган аңа эчемлек…
Шәрәбеме, әллә сәбәбеме,
Андый савытсыз да эчерлек.

Бәллүр савыт купшы сүзләр кебек,
Грузин чәе, кытай савыты…
Чәкештерү өчен күп вакытта,
Ишетелсенгә чынлы тавышы.

Күтәрүләр бәллүр савытларны,
Юылмаслык булган кулларда.
Чебен кебек оча ялагайлар,
Мактар өчен кирәк булганда.

Бәллүр савыт, бәллүр язмыштыр,
Төшеп китсә, бик тиз уалыр…
Булганыда бик тиз онытылып,
Кеше хәтереннән югалыр.

Кеше күңеле тирән урнашкан,
Бәллүр савыт, «конфет кагәзе».
Конфет урынында кайвакытта,
Камыр төргән купшы кагәзе.

# Талантмы…

Тормышлар шулай корылган,
Кешеләргә сәләт биргән.
Өйрәнүгә булган хәҗәт…
Тумышыннан әллә килгән.

Атлый алмый, йөгерә белә,
Сөйли белми, моңлы жырлый.
Матур итеп ялган сөйли,
Ялганнарны тыныч тыңлый.

Әллә ниләр, белеп уйный,
Никтер алар, белми уйлый.
Күп ашаган никтер туймый,
Белмәгәнен читкә куймый.

Акча булса, акыл булмый,
Акыл булса, акча тормый.
Көнгә ошаш, көннәр булмый,
Кирәкмәгән бер көн булмый.

Сирәк була, «булдырганнар»,
Бар яктанда «сындырганнар»…
Яшерелгән бриллианттай,
Сәләтләре мул булганнар.

Төрле, төрле сәләтлеләр,
Эшкәртелгән алмаз кебек.
Кирәк икән андыйларга,
Белмәгән эш калмас кебек.

# Кызган, аз гына

Мөләемдә була ала кеше…
Шул ук бәндә була кыргыйда.
Юмартлыкта ясый вакыт вакыт,
Җае килгән саен, урлыйда.

Ике холык бергә яшәгәндәй,
Күңел шайтан белән сөйләшә.
Тыныч кебек булып калсаларда,
Күп вакытта алар көрәшә.

Ике фикер бергә туа алмый,
Бер берсенә булып карышы.
Тынычлыкны бирә ала мени,
Шайтан юлларыннан барышы.

Аныда бит җинеп яшәгәннәр,
Җиңеп яши күпме кәвәмнәр.
Куа алып, очыраган саен…
Иман белән булган дәвердән.

Бер җан өчен ике фикер авыр,
Шикле әйбер юлдан яздыра.
Бер әйберне бары аңлау җитә:
– «Шайтан юлы бары саз гына».
Үз җаныңны кызган, аз гына!

# Карлар көрим

Көрим әле чыгып,
Яңа яуган карын…
Әллә миңа гына,
Карлар быел калын.

Көндә ата торган,
Карлар яуган таңын.
Аңлый, аңлый яшим,
Кыш чыгасы барын.

Кардан… тоеп калып,
Анда нидер барын.
Аклык эчләрендә,
Яшерелгән тагын.

Кереп чыккан кебек,
Кышлар суыгына.
«Көри» бөтен карны,
Язның суы гына.

Көрим әле көрим,
Яуган карлар булса.
Минем өлешемә,
Тагын яуган булса.

# Кар астында

Менә тагын карлар яуган,
Бер урын юк кар ятмаган…
Сукмакларны без йөрегән,
Ничә еллык кар каплаган.

Кар астында калган эзләр,
Язлар җиткәч эзләнмәгән.
Саклана алып кар астында,
Суынсада, үзгәрмәгән…

Бураннары каплагандай,
Хисләргәдә юллар беткән.
Карлар яуып каплагандай,
Җылысы юктыр… көткән.

Карлар ява, ап ак булып,
Хикмәт кебек ак карларда
Алар белән аралашып,
Хисләр җылы саклангaнга.

# Ихласлык

Авырлыклар җитми инде әллә,
Шуңамы соң кеше узына…
Шөкерсезнең шул вакытта гына,
Ярдәм сорап куллар сузыла…

Өйрәнә алмый, шөкер, тәүбәгә,
Минеке диеп бөтен тапканын.
Аңламыйча күңел төпләрендә,
Иң зур байлык, иман ятканын.

Аллаһ йортларына мохтаҗлыкта,
Сыналауның шактый зурысы.
Кайвакытта тигез җир өстедә,
Мәчетләрнең, кебек олысы.

Мәчетме соң намаз укылмаса,
Аста йозак, өстә манара…
Ябык манарадан ничек итеп,
Азан тавышлары тарала…

Ихласлыкта, бары ихласлыкта,
Кеше күңелләре сынала…
Иң беренче үзен алдамаса,
Имансызлыктан ул чыга ала.

# Тупик

Товар вагонына паровозның
Төягәннәр безне шикелле.
Туктап торабызмы… Барабызмы,
Кайсы якка таба кителде…

Кеше мәшгуль әлләниләр белән,
Һәр кешенең, башы урында.
Уйламыйда, бәлки уйлый алмый,
Үзе утырган вагон турында.

Уенчыклар бүлеп бирелгәндәй,
Аерыла алмас гаджетлар…
Аралашып, буталышып беткән.
Кара җепләр белән ак җепләр.

Байлар баеый, халык бөлә бара,
Акырынлап мохит үзгәрә.
Дошман диеп ябып куеп була,
Риза булмый әйткән сүзгәдә.

Ябаргада безне кирәк түгел,
Үзебезне, үзебез ябабыз.
Кая барганнарны сорый алмый,
Ябык вагоннарда калабыз.

# Мирас

Дөньялыкта ниләр кала ала,
Кешедән соң ниләр сакланыр.
Киткәннәрне искә төшерик без,
Аңлау бәлки шуннан башланыр.

Шаулап үтеп китә тамашалар,
Җирдә кала, яңа язмышлар.
Милегеме, калып кадереме,
Бездән алда булган язмыштан…

Өстәләме безнең яшәүләрдә,
Ул халәтне аңлый алырлык.
Файда яки үрнәк булыр өчен,
Бездән соңда җирдә калырлык.

Табыламы, төртеп күрсәтерлек,
Яшерелеп… бәлки күңелдә…
Тормыш итүләрнең дәлилләре,
Ниләр, кемнәр табын түрендә.

Агы кала, кала карасыда…
Төгәл генә, кинәш юк аңа.
Саваплысы савап булып кала,
Файдасызы… барда югала.

# Язмыш бүлү

Язмыш бер ул! Нигә аны бүлү,
Нигә аны, кирәк вакларга…
Кисәкләргә бүлгәләми генә,
Тулы килеш кирәк сакларга.

Син хуҗадыр үзе язмышыңа,
Кеше язмышына кагылма.
Чарасызлык карышына басып,
Бүленергә торган чагында.

Киселгәнне ялгаулары авыр,
Ул бит була, инде ялгаулы.
Күпме генә дөрес гамәлләрдә,
Каплый алмый булган алдауны.

Язмыш, тавар, алып сату түгел,
Кичерми ул булган ялгышны,
Яхшы диеп әйтеп була мени,
Башканыкын бозган язмышны.

Язмыш булып кеше җиргә килә,
Язмышының була көзләре…
Үзе китә, хәтерләрдә кала,
Язмыш булып җирдә эзләре.

# Хаклык

Дөнья камил итеп яратылган,
Бар кеше өчен җирдә урын бар.
Язмышында, кеше сайлый ала,
Төрле юллар, төрле урыннар.

Гаделлектә, гаlелсезлегедә,
Төрле сыйфатлары туплана.
Кайсыларын кирәктә санамый,
Кайберләре белән «туклана».

Кимчелекләр эзләп яшәгәндә,
Шуны җыеп тулса күңелләр.
Якты хисләр бары били ала,
Булса урын күңел түреннән.

Кимчелек ул нидер җитмәгәннән,
Вакыт табылмаган өчендә…
Тырышуың яки катнашмавың,
Дөнья матурлыгы өченгә…

Күңелеңдә икән, акылыңда,
Яшәүләргә булган карашың…
Тапмаганнар – димәк язмаган,
Булганнары белән барасың…

Дөнья камил, дөрес аңлаганда,
Адашканга… гәеп юлдамы?
Шөкер сүзе шуңа ишетелми,
Җитә алмаганда булганы…

# Озын кыска юл

Берәү белми алда ни буласын,
Олы хыялларың булсада..
Өметеңә канат кебек булып,
Тигез юллар алда торсада.

Вак мәшәкать сине абындыра,
Уйламаган җирдә тоткарлый.
Тукталганда, калып исрафта…
Вакыт әйләнеше тукталмый.

Парлашулар белән аңлашулар,
Үзгәртәләр барсын тамырдан.
Яңа бурыч, яңа вәкаләтләр,
Икмәк пешергәндәй камырдан.

Читкә куеп булган хыялларны,
«Кирәк» сүзе боерык шикелле…
Үтеп китеп, шикле сукмакларны,
Олы юлга чыгып җителде.

Анда инде үзе кануннары,
Юл читләре тирән канаулар.
Күп вакытта төркем үзәгендә,
Чакрымнарын бары санаулар.

Кыскамы соң, әллә бик озынмы,
Язмышлары булган юлларың.
Үлчәмнәре аның языладыр,
Гамәл булып җирдә кылганың.

# Ул чаклар

Әллә ничек үтеп китте,
Гомерләрнең яшь чагы.
Ул вакытлар булды микән,
Күңелләрнең таш чагы.

Юлсыз җирләр, басмалары,
Капкан саен калҗалар…
Андый шаулы вакытлардан,
Күңел күптән алҗаган…

Җырларыда җырланмыйлар,
Яшь чакларны сагынып.
Нигә сагынулар кирәк,
Йөргән кебек ялынып.

Без ялынып яшәмәдек,
Яшәсәктә абынып.
Була иде күп вакытта,
Ялгышлардан арынып.

Агымсулар… сазлыклары,
Коры килеш калмаска.
Өйрәнелде кайбер җиргә,
Ике тапкыр бармаска.

Горур булып яшәлсәдә,
Яшлегедә үтелгән
Ничек кенә яшерсәктә…
Сагынылып кителгән

# Китү, кайту юллары

Юллар белән бәйле бөтен гомер,
Юллар кебек алар сузыла…
Кайткан чакта туган якларыңа,
Кабатланып, юллар узыла.

Китү белән, таныш юлларыңны,
Ничә тапкыр кайтып үтүләр.
Ничә тапкыр озатулар булып,
Кайтуларны кабат, көтүләр.

Гомер юлы кабатланмаса да,
Җирдә юллар тормый ябылып.
Ул юлларны онытмаска була,
Яшәмичә мәңге сагынып.

Юлдагылар гына үзгәрәләр,
Юлчылары тора өстәлеп.
Үткәнедә кала, ул юлларда,
Кабатланганнары өстәлеп.

Калмасада үткән эзең юлда,
Юллар шахит синең сәфәргә.
Сирәккенә… кайтып килүеңә…
Кире киткәнеңә шәһәргә…

# Баскыч

Биеклекләр арасында,
Баскычның басмалары.
Булмый калмый беркемнеңдә
Баскычка басмаганы.

Баскычтан күтәреләләр,
Баскычлардан төшәләр.
Аска таба, өскә таба,
Вакыт вакыт күчәләр.

Үзе атлап, кем тырыша,
Кемгәдер булышалар.
Еш кына сыеша алмый,
Баскычта сугышалар.

Кемдер менсә, төшә белми,
«Ярдәмчеләр» табыла..
Тау башыннан төшү өчен,
«Туры юллар салына».

Баскычларда сикерешү,
Бер туктамый, кыендыр.
Баскычлар олы язмышта,
Бер гәепсез уендыр…

# Февраль

Гыйнвардан февральгә күчтек,
Карлар явып, булды бураннар.
Күп булганга, кадередә юкка,
Карлар белән тулган урамнар.

Кышның төсен, сиздек суык исен,
Тоя алдык салкын җилләрен.
Суыклары, рәхәт булмасада,
Көттек бит без кышның килгәнен.

Яңгырлары булса җәйләрендә,
Кышын буран белән карлары.
Рәсемедәй булып истәлеккә,
Кар өстендә эзләр калганы.

Кар өстеннән генә юлларыда,
Ап ак төстә бөтен матурлык.
Кар юрганы салкын булмаганда,
Күккә карап аунап ятырлык..

Карлы таулар чаңгы, чаналарга,
Шомарылган боздан шугалак.
Кыш көннәре әле дәвам итә,
Калыр өчен тауда шугалап.

# Ялгыз, сәләмсез

Мөмкинме соң ялгыз булу җирдә,
Ялгызлыкта кыйнап күңелне.

# Конец ознакомительного фрагмента.

Текст предоставлен ООО «ЛитРес».

Прочитайте эту книгу целиком, купив полную легальную версию на ЛитРес.

Безопасно оплатить книгу можно банковской картой Visa, MasterCard, Maestro, со счета мобильного телефона, с платежного терминала, в салоне МТС или Связной, через PayPal, WebMoney, Яндекс.Деньги, QIWI Кошелек, бонусными картами или другим удобным Вам способом.